# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Вәрәшбаш авыл җирлеге Вәрәшбаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

16 ноябрь 2023 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2023 елның 16 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2024 елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге Вәрәшбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500,00 (бер мең биш йөз сум) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 750,00 (җиде йөз илле сум) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт нигезендә хезмәт итүче гражданнарны шулай ук хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

1). Вәрәшбаш авылында халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, спорт мәйданчыклары (футбол мәйданчыгы) һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү.

- Кооператив урамында спорт мәйданчыгы төзелеше;
- төзелеш материаллары сатып алу һәм Сабантуй паркын төзекләндерү.
- халыкның күпләп ял итү урыннары территорияләрендә үлән чабу;

2). Урам яктырту челтәрләрен көйләү:

- урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү. Беренче Май, Кооператив һәм Комсомол урамнарын яктырту өчен светодиодлы лампалар сатып алу, урнаштыру;

3). Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм Вәрәшбаш авылында яшәүчеләргә су бирүне тәэмин итү:

- су белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау, материаллар сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү;
- су башнясын караучыга килешү буенча хезмәтләре өчен түләү;
- су башнясының электр энергиясе өчен түләү;
- анализга су алу .

4). Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру.

5). 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга куелган һәйкәлне ремонтлау һәм аңа якын территорияне төзекләндерү ;

6). Вәрәшбаш торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау һәм тоту:

- җәйге вакытта юл кырларындагы үләнне чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторчыга хезмәт хакы);
- Комсомол, Кооператив урамының асфальт өлешендәге чокырларны

ремонтлау.

- Беренче Май, Кооператив, Комсомол урамнарында вак таш белән капланган юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу , тракторчыга хезмәт хакы, ягулык-майлау материаллары);

- Беренче Май, Кооператив, Комсомол урамнарында кышкы һәм җәйге вакытта авыл эчендә юлларны тоту(штаттан тыш хезмәткәргә (тракторчыга) хезмәт хакы түләү, ягулык-майлау материаллары өчен түләү, «Беларус " тракторы өчен запас частьләр һәм өстәмә җиһазлар сатып алу);

- Беренче Май, кооператив, Комсомол урамнарында җәйге вакытта юлларны грейдирлау.

7). Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү ("Салкын Чишмә", "Тәпти", "Исрафил "чишмәләре)

8). Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймa тоту:

- зираттан каты коммуналь калдыклар чыгару;
- койма буяу;
- үлән чабу (ягулык-майлау материаллары, бензотриммер сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү);
- карт агачларны кисү

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 165 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 92, бу 55% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 90 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 2 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегенең Вәрәшбаш торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2023 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегенең Вәрәшбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500,00 (бер мең биш йөз) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 750,00 (җиде йөз илле) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт нигезендә хезмәт итүче гражданнарны шулай ук хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә.

3. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

1). Вәрәшбаш авылында халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, спорт мәйданчыклары (футбол мәйданчыгы) һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү.

- Кооператив урамында спорт мәйданчыгы төзелеше;
- төзелеш материаллары сатып алу һәм Сабантуй паркын төзекләндерү.
- халыкның күпләп ял итү урыннары территорияләрендә үлән чабу;

2). Урам яктырту челтәрләрен көйләү:

- урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү. Беренче Май, Кооператив һәм Комсомол урамнарын яктырту өчен светодиодлы лампалар сатып

алу, урнаштыру;

3). Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм Вәрәшбаш авылында яшәүчеләргә су бирүне тәэмин итү:

- су белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау, материаллар сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү;

- су башнясын караучыга килешү буенча хезмәтләре өчен түләү;

- су башнясының электр энергиясе өчен түләү;

- анализга су алу .

4). Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру.

5). 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга куелган һәйкәлне ремонтлау һәм аңа якын территорияне төзекләндерү ;

6). Вәрәшбаш торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау һәм тоту:

- җәйге вакытта юл кырларындагы үләнне чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторчыга хезмәт хакы);

- Комсомол, Кооператив урамының асфальт өлешендәге чокырларны ремонтлау.

- Беренче Май, Кооператив, Комсомол урамнарында вак таш белән капланган юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу , тракторчыга хезмәт хакы, ягулык-майлау материаллары);

- Беренче Май, Кооператив, Комсомол урамнарында кышкы һәм җәйге вакытта авыл эчендә юлларны тоту(штаттан тыш хезмәткәргә (тракторчыга) хезмәт хакы түләү, ягулык-майлау материаллары өчен түләү, «Беларус " тракторы өчен запас частьләр һәм өстәмә җиһазлар сатып алу);

- Беренче Май, кооператив, Комсомол урамнарында җәйге вакытта юлларны грейдирлау.

7). Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү ("Салкын Чишмә", "Тәпти", "Исрафил "чишмәләре)

8). Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, койма тоту:

- зираттан каты коммуналь калдыклар чыгару;

- койма буяу;

- үлән чабу (ягулык-майлау материаллары, бензотриммер сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү);

- карт агачларны кисү.

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Вәрәшбаш авыл җирлеге башлыгы З.З.Галиева